## Пычак авыл җирлеге Советы

## КАРАР

28 гыйнвар 2021 ел № 1

Пычак авыл җирлеге Советының 2014 елның 27 гынварыннан 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Пычак авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Пычак авыл җирлеге Советының 2014 елның 27 гыйнварыннан 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә, 18.1 статьясын түбәндәге нигездә бәян итеп, (Янил авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 41 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 16 номерлы, 2019 елның 20 февралендәге 4 номерлы, 2019 елның 29 августындагы 21 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), үзгәрешләр кертергә:

«18. 1. Җир кишәрлекләренең чик күләме:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв. м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең максималь күләме– 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Җирлек башлыгы Г.Ш.Нафиков